**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 23 июнь № 416

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социаль ипотека системасында торак төзү өчен түләүсез бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеген раслау хакында» 2008 ел, 4 август, 559 нчы карары белән расланган Дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социаль ипотека системасында торак төзү өчен түләүсез бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социаль ипотека системасында торак төзү өчен түләүсез бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеген раслау хакында» 2008 ел, 4 август, 559 нчы карары белән расланган Дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социаль ипотека системасында торак төзү өчен түләүсез бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктның алтынчы абзацында «җир кишәрлегенең кадастр паспорты» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан тиешле җир кишәрлеге турында өземтә» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче пунктның бишенче абзацында «җир кишәрлегенең кадастр паспорты» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан тиешле җир кишәрлеге турында өземтә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\416.docx